ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2021 508

Алабуга муниципаль районы территориясендә
хөкем ителүчеләр тарафыннан төзәтү һәм мәҗбүри
эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен эш төрләрен,
объектларын һәм урыннарын билгеләү турында

Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49, 50 статьялары һәм Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 25, 39 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:
- хөкем ителүчеләр тарафыннан төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен эш төрләрен (1 нче кушымта).
- хөкем ителүчеләр тарафыннан төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен эш урыннарын (килешү буенча) (2 нче кушымта);
- хөкем ителүчеләр тарафыннан төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен эш объектларын (килешү буенча) (3 нче кушымта);
2. Әлеге карарга теркәлгән 1, 2, 3 нче кушымталардан чыгып предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:
- «Россия җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе» Федераль казна учреждениесенең Алабуга муниципальара филиалында исәптә торучы, төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза алырга хөкем ителгән затларны, «Россия җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе» Федераль казна учреждениесенең Алабуга муниципальара филиалы тарафыннан төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгән затларга бирелгән юллама нигезендә, хөкем ителгәннәргә кимендә бер эш урыны булдыруны, шулай ук кирәкле хуҗалык инвентаре һәм материаллары белән тәэмин итүне;
- «Россия җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе» Федераль казна учреждениесенең Алабуга муниципальара филиалы запросы (соратуы)

буенча төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза алырга хөкем ителүче затларга өстәмә эш урыннары булу һәм (яки) ачылган буш вакансияләр турында мәгълүмат бирүне.

3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә административ җәзаны һәм хөкем ителүчеләр тарафыннан төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен эш турыннарын билгеләү турында» 2017 елның 15 ноябрендәге 1412 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 508 ” 14.04.2021 ел

карарына 1 нче кушымта

**Хөкем ителүчеләр тарафыннан төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен эш төрләре**

- хөкем ителүчеләрнең белгечлекләре буенча эш;
- урам, парк, шәһәр һәм район скверларын, йорт яны биләмәләрен, торак йортларның подъездларын җыештыру;
- территорияләрне төзекләндерү, санитар чистарту һәм яшелләндерү;
- агачларны һәм каймаларны агарту;
- автомобиль юлларын, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, чәчәк түтәлләрен (газоннарны) карап тоту һәм җыештыру;
- биналарны, корылмаларны ремонтлау һәм карап тоту, җыештыру;
- йөк төяү-бушату эшләре;
- зират территорияләрен җыештыру;
- сантехника эшләре, белгечлек таләп ителмәгән буяу, агарту эшләре һәм агач, балта эшләре;
- башка ярдәмче эшләр;
- кисү өчен урман бүлемтекләрен (кишәрлекләрен) билгеләү (урман корылышы билгеләре, кисү яки чистарту аралыкларын, баганаларын әзерләү һәм урнаштыру);
- яшь агач үсентеләрен тәрбияләү, кисү (чистарту, яктырту);
- урман фонды территориясен төзекләндерү (урман кишәрлекләрен коммуналь калдыклардан чистарту, коры-сарыдан һәм ауган агачлардан чистарту, ял итү мәйданчыгы, беседкалар урнаштыру һ.б.);
- урман культуралары җитештерү (Колесов кылычы белән урман культураларын кулдан утырту, агач утыртканда үсентеләрне чәчү аппаратына бирү, үсентеләрне утырту машинасы артыннан утырту, урман культураларын тулыландыру, урман культуралары мәйданнарын табигый бизәгәндә эшлекле баганалар әзерләү һәм урнаштыру, урман культураларын кулдан агротехник тәрбияләү);
- урманнарында авиация һәм җир өсте ысуллары ярдәмендә зарарлы организмнар санын локальләштерү чаралары уздырганда һәм аларны юкка чыгару эшләре башкарганда агрегатларга эш эремәләре салу;
- урман янгыннарын җир өсте юлы белән сүндерү.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 508 ” 14.04.2021ел
карарына 2 нче кушымта

**Хөкем ителүчеләр тарафыннан мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү өчен эш урыннары (килешү буенча)**

1. «АлАЗ» ҖАЖ
2. «Кама буе нефте» нефть-газ чыгару идарәсе
3. «Автомастер» ҖЧЖ
4. «Алабуга керамикасы» ААЖ
5. «Алабуга ҖЧП» ААЖ
6. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районын төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе» МУП
7. «Мехуборка» ҖЧЖ
8. «Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» ААЖ
9. «КамПолиБэг» ҖЧЖ
10. «Алабуга бөкеләү һәм пластмасса эшләнмәләр предприятиесе» ҖЧЖ
11. ЗАО «Эссен – Продакшн АГ»
12. «Тракья-Гласс Алабуга» ҖЧЖ
13. «Алабуга азык-төлек комбинаты» ЯАЖ
14. «Алабуга сөт комбинаты» ҖЧЖ
15. «Алабуга ит комбинаты» ҖЧЖ
16. «Град Сервис» ҖЧЖ
17. «МСК Квазар» ҖЧЖ
18. «Клининг Эксперт» ҖЧЖ
19. «ВодПром» ҖЧЖ
20. «Нефтегазокомплект» ҖЧЖ
21. Алабуга районының авыл хуҗалыгы оешмалары
22. «Домуправ-1» ҖЧЖ
23. Алабуга муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары
24. Алабуга муниципаль районының крестьян-фермер хуҗалыклары
25. «ТракДизельМоторс» ҖЧЖ
26. «Алабуга» ТЭК ҖЧЖ
27. «ПродЛайф» ҖЧЖ
28. «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» ААЖ (су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләре)
29. Алабуга муниципаль районының «ТКХ һәм төзелеш Департаменты» МУП
30. «Жилкомфортсервис» ҖЧЖ

31. Предприятиеләр - «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» ААҖ резидентлары
32. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы идарәче компанияләр
33. Торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү өлкәсендәге эшчәнлекне Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыручы оешмалар
34. Алабуга районының шәхси эшкуарлары.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 508 ” 14.04. 2021 ел
карарына 3 нче кушымта

**Хөкем ителүчеләр тарафыннан мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү өчен эш объектлары (килешү буенча)**

1. «АлАЗ» ҖАЖ
2. «Автомастер» ҖЧЖ
3. «Алабуга керамикасы» ААҖ
4. «Алабуга ҖЧП» ААҖ
5. «Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» Бехтерев исемендәге бүлек ярдәмче хуҗалык
6. «КамПолиБэг» ҖЧҖ
7. «Алабуга бөкеләү һәм пластмасса эшләнмәләр предприятиесе» ҖЧҖ
8. «Алабуга тәм-томнары» ҖЧҖ
9. «Алабуга сөт комбинаты» ҖЧҖ
10. «Алабуга ит комбинаты» ҖЧҖ
11. «СтройРемонт» ҖЧҖ
12. Алабуга районының авыл хуҗалыгы оешмалары
13. Алабуга муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары
14. Чистый Дом ҖЧҖ
15. «Домуправ-1» ҖЧҖ
16. Предприятиеләр - «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» ААҖ резидентлары
17. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы идарәче компанияләр.
18. Торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү өлкәсендәге эшчәнлекне Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыручы оешмалар.